
**Кешенең иң зур бәхете – иң камил җан иясе булып дөньяга килүе һәм яшәве.**



**Шәриф Хөсәенов**
**(1929 – 1999)**



# Ш. Хөсәеновны драматург буларак танытткан әсәрләр





- “Профессор кияве” (1952)
- “Бирнәле кыз” (1954)
- “Зөбәйдә – адәм баласы” (1961)
- “Егерме ел үткәч” (1962)
- “Әниемнең ак күлмәге” (” Әни килде” )(1968)



**“Зөбәйдә – адәм баласы” трагикомедиясе (1961)**
**(Беренче куелыш)**
**Зөбәйдә ролендә – Наилә Гәрәева**
***Кешеләр! Сез Зөбәйдәгә дөрес юлны сайларга булышыгыз, аны сукмактан читкә этәрмәгез!***



*Г. Камал театры.*

*“Әни килде” Беренче куелыш. (1970).*

*Ана ролендә – Галимә Ибраһимова.*

Ана йөрәге барысын да сыйдыра.



Г. Камал театры.

“Әни килде”. Икенче куелыш.(1999)

Ана ролендә –

Наилә Гәрәева



# Дәреснең темасы:
# “Әни килде” драмасына анализ



## Драма әсәренә анализ ясау тәртибе

1. Эчтәлекне кыскача сөйләп чыгу.
2. Төп һәм ярдәмче конфликтларны билгеләү.
3. Геройларны өйрәнү.
4. Әсәрне өлешләргә бүлү.
5. Өлешләр арасындагы бәйләнешне ачыклау.
6. Идеяне билгеләү

**Конфликт** – вакыйга-күренешләр, хәрәкәт нигезенә салынган характерлар һәм хәлләр, карашлар бәрелеше. Ул:

- кешеләр арасында
- кеше һәм тирәлек арасында
- кеше һәм яшәү рәвеше арасында
- кешенең үз эчендә булырга мөмкин.

# Әсәрдәге конфликтлар

Сәяр ⟺ туганнары

**Ана һәм балалар мөнәсәбәте**

**Ана** ***балаларының барысын да тигез күрә, аерым-аерым хәлләрен сораша,***

**ләкин**

***балалар үзләрен күбрәк кайгырталар***

# Зөләйха образы

***Бик игелекле кеше ул. Үзенең сугышта үлгән иренең этисе Әлмөхәммәт бабайны да тәрбияли. Авыру Ананы больницага салучы да, больницадан чыккач үз өендә караучы да Зөләйха апа була.***

# Әсәрдәге конфликтлар

Сәяр ⟺ Римма

Туганнар ⟺ Римма

Туганнар ⟺ Максуд, Саимә

Туганнар ⟺ Ислам, Расиха

Туганнар ⟺ Гөлчирә

Туганнар ⟺ Инсаф

# Эчке конфликт

**Ана күңелендә балаларына карата көчле мәхәббәт бар,**

**тик**

**аларга карата үпкәсе дә зур.**

# Әсәрдәге метафоралар

**Ак шәл**

**Ак яулык**

**Ак күлмәк**

**Ак кар**

**Әсәрнең идеясе нинди?**

**Намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен кеше булу кирәк.**

“Кеше булыгыз! Куркак җан булудан сакланыгыз! Кеше куркак бул-са, үзенең җанын саклап калу өчен, теләсә нинди түбәнлеккә бара. Атасын да, анасын да ,хәтта Ватанын да сата!..”

## Драмада күтәрелгән мәсьәләләр:

*-балаларның Анага карата бурычы;*

*- гаилә төзүгә җиңел караш;*

*- гаиләдә бала тәрбиясе;*

*- туганнар арасында җылы мөнәсәбәт*

**«Адәм баласы дөньягә килүе өчен әти – әнисенә бурычлы. Ата – анага бурычны бары тик Кеше булып кына түләп була.**

***(Т. Миңнуллин)***

# Ш. Хөсәенов иҗаты үлемсез



Мин үлгәч, каберем өстендә сиреньнәр чәчәк атсын. Узган –барган юлыксын да кайгыларын онытсын.

Ш. Хөсәенов

## Өй эше

**Әниләр, ана һәм бала мөнәсәбәте турында 5 мәкаль язып килергә һәм аңлатырга әзерләнергә**